КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 апрель г.Казань № 303

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карары белән расланган 2019 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 2 март, 161 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә, 7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян тиеп, үзгәреш кертергә:

«оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затларга һәм социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма «Сиделка" хезмәте

өчен дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган индивидуаль эшмәкәрләргә чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү».

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин